**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

18.07.2018 № 242

**О мерах по реализации отдельных положений Федерального закона «О противодействии коррупции», касающихся ведения реестра лиц, уволенных в связи с утратой доверия**

В соответствии со статьей 15 Федерального закона от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ «О противодействии коррупции», постановлением Правительства Российской Федерации от 5 марта 2018 года № 228 «О реестре лиц, уволенных в связи с утратой доверия»:

1. Кабинету Министров Республики Татарстан:

определить должностное лицо, ответственное за включение сведений о лицах, замещавших государственные должности Республики Татарстан, муниципальные должности в Республике Татарстан, должности государственной гражданской службы Республики Татарстан и должности муниципальной службы в Республике Татарстан, к которым было применено взыскание в виде увольнения (освобождения от должности) в связи с утратой доверия за совершение коррупционного правонарушения, в реестр лиц, уволенных в связи с утратой доверия (далее – Реестр), и исключение сведений из него посредством направления этих сведений в уполномоченное подразделение Аппарата Правительства Российской Федерации;

представлять сведения, указанные в абзаце втором настоящего пункта, в Департамент государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан для проведения проверки их достоверности и полноты;

обеспечить своевременное направление сведений, указанных в абзаце втором настоящего пункта, в уполномоченное подразделение Аппарата Правительства Российской Федерации в соответствии с Положением о реестре лиц, уволенных в связи с утратой доверия, утвержденным постановлением Правительства Российской Федерации от 5 марта 2018 года № 228 «О реестре лиц, уволенных в связи с утратой доверия» (далее – Положение).

2. Руководителям государственных органов Республики Татарстан:

определить должностное лицо, ответственное за направление в Кабинет Министров Республики Татарстан сведений о лицах, замещавших государственные должности Республики Татарстан и должности государственной гражданской службы Республики Татарстан

в соответствующем государственном органе Республики Татарстан, к которым было применено взыскание в виде увольнения (освобождения от должности) в связи с утратой доверия за совершение коррупционного правонарушения, для включения этих сведений в Реестр, а также для исключения их из Реестра;

обеспечить своевременное направление сведений, указанных в абзаце втором настоящего пункта, в Кабинет Министров Республики Татарстан в соответствии с Положением.

3. Рекомендовать руководителям органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан:

определить должностное лицо, ответственное за направление в Кабинет Министров Республики Татарстан сведений о лицах, замещавших муниципальные должности и должности муниципальной службы в соответствующем органе местного самоуправления муниципального образования Республики Татарстан, к которым было применено взыскание в виде увольнения (освобождения от должности) в связи с утратой доверия за совершение коррупционного правонарушения, для включения этих сведений в Реестр, а также для исключения их из Реестра;

обеспечить своевременное направление сведений, указанных в абзаце втором настоящего пункта, в Кабинет Министров Республики Татарстан в соответствии с Положением.

4. Департаменту государственной службы и кадров при Президенте Республики Татарстан обеспечить проведение проверки достоверности и полноты сведений, указанных в абзаце втором пункта 1 настоящего распоряжения, в течение одного рабочего дня со дня их представления Кабинетом Министров Республики Татарстан.

5. Настоящее распоряжение вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

18.07.2018 № 242

**«Коррупциягә каршы көрәшү турында» Федераль законның ышаныч югалту сәбәпле эштән җибәрелгән затлар реестрын алып баруга кагылышлы аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында**

«Коррупциягә каршы көрәшү турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ышаныч югалту сәбәпле эштән җибәрелгән затлар реестры турында» 2018 елның 5 мартындагы 228 номерлы боерыгы нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары, Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфалар, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары биләүче, аларга карата коррупцион хокук бозган өчен ышаныч югалту сәбәпле эштән җибәрү (вазыйфасыннан азат итү) рәвешендә җәза кулланылган затлар турында мәгълүматларны ышаныч югалту сәбәпле эштән җибәрелгән затлар реестрына (алга таба – Реестр) кертүгә һәм әлеге мәгълүматларны Россия Федерациясе Хөкүмәте Аппаратының вәкаләтле бүлекчәсенә җибәргәннән соң Реестрдан төшереп калдыруга җаваплы вазыйфаи затны билгеләргә;

әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматларны аларның дөреслегенә һәм тулылыгына тикшерү уздыру өчен Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына җибәрергә;

әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматларны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ышаныч югалту сәбәпле эштән җибәрелгән (вазыйфасыннан азат ителгән) затлар реестры турында» 2018 елның 5 мартындагы 228 номерлы боерыгы белән расланган Ышаныч югалту сәбәпле эштән җибәрелгән (вазыйфасыннан азат ителгән) затлар реестры турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте Аппаратының вәкаләтле бүлекчәсенә үз вакытында җибәрүне тәэмин итәргә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләренә:

Татарстан Республикасының тиешле дәүләт органында Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфалары биләүче, аларга карата коррупцион хокук бозган өчен ышаныч югалту сәбәпле эштән җибәрү (вазыйфасыннан азат итү) рәвешендә җәза кулланылган затлар турында мәгълүматларны Реестрга кертү, шулай ук аларны Реестрдан төшереп калдыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрүгә җаваплы вазыйфаи затны билгеләргә;

әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматларны Нигезләмә нигезендә үз вакытында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең тиешле җирле үзидарә органында Татарстан Республикасы муниципаль вазыйфалары һәм Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте вазыйфалары биләүче, аларга карата коррупцион хокук бозган өчен ышаныч югалту сәбәпле эштән җибәрү (вазыйфасыннан азат итү) рәвешендә җәза кулланылган затлар турында мәгълүматларны Реестрга кертү, шулай ук аларны Реестрдан төшереп калдыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрүгә җаваплы вазыйфаи затны билгеләргә;

әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматларны Нигезләмә нигезендә үз вакытында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына әлеге боерыкның 1 пункты икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслегенә һәм тулылылыгына тикшерүне аларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тапшырган көннән бер эш көне дәвамында уздыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге боерык аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ